**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисенең аерым указларына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы Рәисенең Территорияләр белән эшләү идарәсе турында нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 17 апрелендәге 240 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы Рәисенең Территорияләр белән эшләү идарәсе турында нигезләмәнең 7 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа унсигезенче абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре башлыклары вәкаләтләрен вакытлыча башкаручылар итеп билгеләп куюю өчен кандидатларның Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында аларга куелган таләпләргә туры килүен тикшерүне оештыру һәм уздыру;»;

б) унсигезенче – егерме җиденче абзацларны тиешле тәртиптә унтугызынчы – егерме сигезенче абзацлар дип санарга.

2. Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе турында» 2023 елның 13 июнендәге 399 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Рәисенең 2025 елның 12 маендагы 355 номерлы һәм 2026 елның 15 апрелендәге 296 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе турында нигезләмәнең 6 пункты «л» пунктчасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре башлыклары вәкаләтләрен вакытлыча башкаручылар тарафыннан керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында бирелгән белешмәләренең дөреслеген һәм тулылыгын;».

3. Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты турында» 2023 елның 19 июнендәге 411 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Рәисенең 2025 елның 12 маендагы 355 номерлы указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы

Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты турында нигезләмәнең 7 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче абзац өстәргә:

«Гавами хакимият бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге башлыгы вәкаләтләрен вакытлыча башкаручыны билгеләп кую турында указлары проектларын билгеләнгән тәртиптә әзерләү;»;

б) дүртенче – җитмеш бишенче абзацларны тиешле тәртиптә бишенче – җитмеш алтынчы абзацлар дип санарга.

4. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2026 ел, 30 июнь
№ 521